**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы, 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» сентября 2024 ел № 411

**Әтнә районы Башкарма комитетының «муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2021 елның 30 сентябрендәге 408 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 14.07.2022 ел, №312-ФЗ Федераль законга таянып, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 25.12.2023 №627-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»28.02.2022 елның 175 номерлы карары нигезендә Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Әтнә район башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 30.09.2021 №408 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның преамбуласында “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән” сүзләрен “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында” 28.02.2022 № 175 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән” сүзләре белән алыштырырга;

1.2. Административ регламентның 2.8.2.1 пунктындагы 8-10 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

8) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән йә аны комплекслы

үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, моңа җир кишәрлеген бирү турында гариза белән бина, корылма, биналар милекчесе, мондый җир кишәрлегендә урнашкан төгәлләнмәгән төзелеш объекты яисә мондый җир кишәрлегенең хокукый иясе мөрәҗәгать иткән очраклар керми;

9) җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән булса, моңа карата мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектлар, региональ әһәмияттәге объектлар яисә җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән булса;

10) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән йә территорияне комплексլы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлегеннән төзелгән, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен каралган булса, моңа җир кишәрлеген арендага бирү турында гариза белән әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тотучы территорияне комплексլы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән булса;»;

1.3. Административ регламентның 2.8.2.1 пунктындагы 13 пунктчасында «бакчачылыкны» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып барулары» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Административ регламентның 3.3.2.1 пунктның 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал гаризаның дөрес тутырылмаган электрон формасы кырын ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әтнә муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Ф.Каюмов